**Татарстан Республикасы Балык Бистәсемуниципаль районы Олы Елга авыл җирлегесоставына керүче Саескан Тавы, Кама поселогы авыл торак пунктларында узган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында КАРАР**

2019 елның 31 октябре № 1

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының ”Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Законының 35 маддәсе нигезендә “Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге составына керүче Саескан Тавы авылы, Кама поселогы торак пунктларында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан һәм 1 төркем инвалидлардан гайре) 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- янгын сүндерү гидрантлары сатып алуга һәм аларны Олы Елга, Казаклар авылларына урнаштыруга;

- Олы Елга, Казаклар, Саескан Тавы авылларындагы су этем скважиналары өчен тирәнлек насослары сатып алуга;

- авыл җирлеге торак пунктларында урам яктырткычлары өчен энергия саклаучы лампалар сатып алуга һәм алыштыруга;

- Олы Елга авылының Яшьләр, Күл, Мәктәп, Нариман, Совет, Чишмә, Яңа-2, Мөхәммәтгали урамнарындагы юлларны ремонтлауга;

-кышын авыл җирлеге торак пунктларында урамнарның йөри торган өлешләрен карап торуга (кардан арындыруга);

- Олы Елга авылының Яшьләр урамында “Бизнә” инеше аша салынган җәяүлеләр күперен ремонтлауга?“ соравы (мәсьәләсе) буенча 2019 елның 31 октябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыенының сайлау хокукына ия катнашучылары исемлегенә 64 кеше кертелде, тавыш бирүдә җыенның 33 кешесе катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

“Әйе”позициясе өчен 33 җыенда катнашучы тавыш биргән;

“Юк”позициясе өчен 0 җыенда катнашучы тавыш биргән.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены **КАРАР БИРӘ:**

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге составына керүче Саескан Тавы авылы, Кама поселогы торак пунктларында гражданнар җыеннарын булды дип, гражданнар җыеннары нәтиҗәләрен **дөрес** дип танырга.

2.“Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге составына керүче Саескан Тавы авылы, Кама поселогы торак пунктларында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән

(уку йортларына йөреп укучы студентлардан һәм 1 төркем инвалидлардан гайре) 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- янгын сүндерү гидрантлары сатып алуга һәм аларны Олы Елга, Казаклар авылларына урнаштыруга;
- Олы Елга, Казаклар, Саескан Тавы авылларындагы су этем скважиналары өчен тирәнлек насослары сатып алуга;
- авыл җирлеге торак пунктларында урам яктырткычлары өчен энергия саклаучы лампалар сатып алуга һәм алыштыруга;
- Олы Елга авылының Яшьләр, Күл, Мәктәп, Нариман, Совет, Чишмә, Яңа-2, Мөхәммәтгали урамнарындагы юлларны ремонтлауга;
- кышын авыл җирлеге торак пунктларында урамнарның йөри торган өлешләрен карап торуга (кардан арындыруга);
- Олы Елга авылының Яшьләр урамында “Бизнә” инеше аша салынган җәяүлеләр күперен ремонтлауга “ соравы (мәсьәләсе) буенча карарны **кабул ителде** дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Олы Елга авылы, Октябрь урамы, 25 йорт; Казаклар авылы, Үзәк урам, 9 йорт; Саескан Тавы авылы,Үзәк урам,16А йорт; Кама поселогы, Курорт-2 урамы, 23 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

4. Карарны Татарстан Республикасы үзидарәлек хокукый норматив актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Олы Елга авыл җирлеге башлыгы Ф.А.Садриев